| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 29 » 04 2021 № 134

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарны исәпкә куйганда һәм аларга торак биргәндә торак мәйданы нормалары турында» 2009 елның 30 декабрендәге 329 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарны исәпкә куйганда һәм аларга торак биргәндә торак мәйданы нормалары турында» 2009 елның 30 декабрендәге 329 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын билгеләргә, шуннан чыгып, аларны торак урынның бер әгъзасына торак урынның гомуми мәйданы 18 кв. метрдан артмаган күләмдә торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урын белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе билгеләнә.».

Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Билгеләргә:

2.1. Дәүләт торак программалары буенча гаиләнең бер әгъзасына 18 кв. метр күләмендә торак урыны мәйданы бирү нормасын, әмма ялгыз яшәүче граждан өчен 33 квадрат метрдан да ким булмаган торак урыны гомуми мәйданы һәм ике кешедән торган гаилә өчен 42 квадрат метрдан да ким булмаган торак урыны гомуми мәйданы күләмен;

2.2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында торак урынының гомуми мәйданының 18 квадрат метр күләмендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасын.».

Карарны түбәндәге эчтәлекле 3нче пункты белән тулыландырырга:

«3. Социаль наем шартнамәләре буенча торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә».

карарның 3нче пунктын тиешле 4нче пункт дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru
бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.И. Исламовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев